# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл жирлеге составына кергән Ачы торак пункты гражданнар жыены нәтижәләре турында

2020 елның 15 ноябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 15 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл жирлеге Ачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кеше, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку бүлеге формасы буенча белем алучы студентлар азатителә, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме, бу сумманың 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидлары, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр түли һәм вак таш юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләү) Ачы авылының Мәктәп, Җиңү урамнары

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 89 катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә җыенда катнашучы гражданнар саны 47 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 47 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына керүче Ачы торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл жирлеге Ачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кеше, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку бүлеге формасы буенча белем алучы студентлар азатителә, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме, бу сумманың 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидлары, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм вак таш юлларны

ремонтлау (сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләү) Ачы авылының Мәктәп, Җиңү урамнары

ӘЙЕ ЮК».

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Иске Чишмә авыл җирлеге сайтына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Әхмәтов

«Совет Старошешминского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»